| | |
|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ** |

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

19.10.2016 № 1123-п

Региональ дәрәҗәдәге объектларга дәүләт экологик экспертизасы оештыру һәм үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы “Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында” Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы “Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” Карары нигезендә боерык бирәм:

1. Әлеге боерыкка кушымтада бирелә торган Региональ дәрәҗәдәге объектларга дәүләт экологик экспертизасы оештыру һәм үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Дәүләт экологик экспертизасы бүлеге башлыгы О.В.Манидичевага Регламентны Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының “Татарстан Республикасы рәсми порталы” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составындагы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Дәүләт экологик экспертизасы бүлегенә (О.В. Манидичева) Регламент нигезләмәләренә тайпылышсыз таянып эш итәргә, эшләрнең Регламентка туры китереп башкарылуын тәэмин итәргә.

4. Хокукый тәэминат бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары Р.И.Камаловка йөкләргә.

Министр Ф.С. Габделганиев

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигый байлыклар
министрлыгының 19.10.2016
№1123-п боерыгы белән расланды

Региональ дәрәҗәдәге объектларга дәүләт экологик экспертизасы оештыру һәм үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
Административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Административ регламент (алга таба – Регламент) региональ дәрәҗәдәге объектларга дәүләт экологик экспертизасын оештыру һәм үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтү).

1.2. Дәүләт хезмәт күрсәтүен алучылар: региональ дәрәҗәдәге объектларга дәүләт экологик экспертизасына (алга таба - дәүләт экологик экспертизасы) материаллар тапшыручы физик затлар, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм аларның территориаль органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары һәм алар ведомствосындагы учреждениеләр, җирле үзидарә органнары.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар Министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

Министрлыкның урнашкан урыны: Казан ш., Павлюхин ур.,75.

Министрлыкның эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән тыш көн саен, дүшәмбе - пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән 18.00 кадәр, җомга 9.00 сәгатьтән 16.45 кадәр, төшке аш 12.00 - 12.45.

Җәмәгать транспортында бару “Павлюхин” тукталышына кадәр:

автобуслар №№ 2, 4, 5, 25, 31, 37, 43, 47, 69, 69а, 74, 74а, 77;

троллейбуслар №№ 6, 8, 12;

метро «Сукно Бистәсе» станциясенә кадәр.

Керү шәхесне таныклый торган документ буенча.

1.4. Министрлыкның дәүләт экологик экспертизасы бүлегенең (алга таба – Бүлек) белешмәләр телефоны: (843) 267-68-31.

Электрон почта адресы: Olga.Manidicheva@tatar.ru.

1.5. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының “Татарстан Республикасы рәсми порталы” дәүләт мәгълүмати системасы составына керә торган рәсми сайты (алга таба – туры китереп, Министрлыкның рәсми сайты һәм «Интернет» челтәре) адресы: http://eco.tatarstan.ru, электрон почта адресы: eco@tatar.ru.

1.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында текстлы информацияләрне үз эченә алган, Министрлык биналарында урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы информация стендлары аша;

2) “Интернет” челтәре ярдәмендә:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://www.eco.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталында: (http://uslugi.tatar.ru/);

Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында: (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон буенча);

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә.

1.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында һәм Министрлык биналарында куелган информация стендларында урнаштырыла.

Информация стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат үз эченә дәүләт хезмәте күрсәтү турында әлеге Регламентның 1.3, 1.4, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында булган мәгълүматларны ала.

1.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Конституциясе (Российская газета, 1993, 25 декабрь, № 237, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2005, № 1, ст.16, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

1995 елның 24 апрелендәге № 52-ФЗ “Хайваннар дөньясы турында” Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 1995, № 17, ст.1462, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

1995 елның 23 ноябрендәге №174-ФЗ “Экологик экспертиза турында” Федераль закон (алга таба - Федераль закон №174-ФЗ) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 1995, № 48, ст.4556, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2002 елның 10 январендагы № 7-ФЗ “Әйләнә-тирә мохитне саклау төрында” Федераль закон (Российская газета, 2002, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2010 елның 27 июлендәге № 210-ФЗ “Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында” Федераль закон (алга таба - Федераль закон № 210-ФЗ) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2010, № 31, ст. 4179, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2011 елның 6 апрелендәге № 63-ФЗ “Электрон имза турында” Федераль закон (Российская газета, 2011, 08 апрель, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы № 601 “Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында” Указы (алга таба – РФ Президенты Указы № 601) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2012, № 19, ст. 2338);

Россия Федерациясе Министрлар Советы - Хөкүмәтенең 1993 елның 22 сентябрендәге № 942 “Дәүләт экологик экспертизасы турында нигезләмәне раслау турында” карары (Россия Федерациясе Президенты һәм Хөкүмәте актлары җыелмасы, 1993, № 39, ст. 3621, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1996 елның 11 июнендәге № 698 “Дәүләт экологик экспертизасын үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау турында”

карары (алга таба - РФ Хөкүмәтенең № 698 карары) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 1996, № 40, ст.4648);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 7 ноябрендәге № 822 “Аларны төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонт ясау аеруча саклана торган табигый территорияләр җирләрендә күздә тотыла торган объектларның проект документларын дәүләт экспертизасы һәм дәүләт экологик экспертизасы үткәрү өчен тапшыру кагыйдәләрен раслау турында” карары (алга таба - РФ Хөкүмәтенең № 822 карары) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2008, № 46, ст.5344, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 16 маендагы №373 “Дәүләт функцияләрен башкаруның административ регламентларын һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау турында” карары (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2011, № 22 ст.3169, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 7 июлендәге № 553 “Дәүләт хезмәтләре һәм (яки) муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм бүтән документларны электрон документлар формасында рәсмиләштерү һәм тапшыру тәртибе турында” карары (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2011, № 29, ст.4479);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 25 июнендәге № 634 “Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр алу өчен мөрәҗәгать иткәндә аларны файдалану рөхсәт ителә торган электрон имза төрләре турында” карары (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2012, № 27, ст. 3744, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 16 августындагы № 840 “Федераль башкарма хакимият органнарының һәм аларның вазыйфаи затларының, федераль дәүләт хезмәткәрләренең, Россия Федерациясе дәүләт бюджеттан тыш фондлары вазыйфаи затларының, шулай ук Атом энергиясе буенча “Росатом” Дәүләт корпорациясенең һәм аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр бирү һәм карау тәртибе турында” карары (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2012, № 35, ст.4829, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 25 августындагы № 852 “Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр алу өчен мөрәҗәгать иткәндә, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза файдалану кагыйдәләрен раслау турында һәм Административ регламентларны эшләү һәм раслау кагыйдәләренә үгәреш кертү турында” карары, (Российская газета, 2012, 31 август, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигый ресурслар министрлыгының 1995 елның 29 декабрендәге №539 ““Хуҗалык һәм бүтән төр эшчәнлекне экологик нигезләү буенча инструкцияләр”не раслау турында” боерыгы (Экологический вестник Москвы, 1996);

Россия Федерациясе Әйләнә-тирә мохитне саклау буенча Дәүләт комитетының 2000 елның 16 маендагы №372 “Ниятләнелә торган хуҗалык һәм бүтән төр эшчәнлекнең Россия Федерациясендә әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү

турында нигезләмәне раслау турында” боерыгы (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, 2000, № 31);

Россия Федерациясе Табигый ресурслар һәм экология министрлыгының 2013 елның 23 сентябрендәге №404 “Дәүләт экологик экспертизасының штаттын тыш экспертларына түләү тәртибен раслау турында” боерыгы (алга таба – РФ Табигать министрлыгының №404 боерыгы) (Российская газета, 2014, 9 апрель);

Россия Федерациясе Табигый ресурслар һәм экология министрлыгының 2014 елның 12 маендагы № 205 “Дәүләт экологик экспертизасын үткәрүгә чыгымнар сметасын билгеләү тәртибен раслау турында” боерыгы (алга таба – РФ Табигать министрлыгының № 205 боерыгы) (Российская газета, 2014, 4 июль);

Татарстан Республикасы Экология кодексы (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2009, № 1, ст. 5, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июлендәге 325 нче номерлы “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре” карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмерләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы” журналы, 2005, № 28, ст. 0654, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 ноябрендәге №880 “Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” Карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба - Тәртип), (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмерләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы” журналы, 2010, № 46, ст. 2144, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.9. Әлеге регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

экологик экспертиза – экологик экспертиза объектын тормышка ашыру белән бәйле рәвештә ниятләнелә торган хуҗалык һәм бүтән төр эшчәнлекне нигезли торган документларның һәм (яки) документациянең, андый эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын булдырмау максатларында, техник регламентлар һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар белән билгеләнә торган экологик таләпләргә туры килүен билгеләү;

гариза бирүчеләр (алга таба – гариза бирүчеләр) - физик затлар, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм аларның территориаль органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары һәм алар ведомствосындагы учреждениеләр, җирле үзидарә органнары;

техник хата – Министрлык тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәт күрсәтүе нәтиҗәсе) кертелгән мәгълүматларның мәгълүматлар керткәндә нигезләнелгән документтагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (ялгыш

язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү һәм бирү, консультацияләр бирү тәрәзәсе.

Әлеге регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә гариза бирүченең № 210-ФЗ Федераль законның 2 статьясының 1 пункты белән каралган дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запросы аңлана. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гаризаның тәкъдим ителгән формасы әлеге Регламентка 1нче кушымтада бирелә.

## 2. **Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты**

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка таләпләрнең эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәт күрсәтүенең атамасы | Региональ дәрәҗәдәге объектларга дәүләт экологик экспертизасын оештыру һәм үткәрү | №174-ФЗ Федераль законның 12 маддәсе; Нигезләмәнең 3.3.6 пункты |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтә торган башкарма хакимият органы атамасы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы (алга таба – Министрлык) | |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | 1. Дәүләт экологик экспертизасының Министрлык боерыгы белән расланган уңай бәяләмәсен бирү.<br>2. Дәүләт экологик экспертизасының Министрлык боерыгы белән расланган тискәре бәяләмәсен бирү.<br>3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат бирү. | №174-ФЗ Федераль законның 18 маддәсе;<br>РФ Хөкүмәтенең № 698 карары |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы, туктатып тору мөмкинлеге Россия | 1. Дәүләт экологик экспертизасын үткәрү срогы өч айдан артырга тиеш түгел һәм гариза бирүченең гаризасы буенча бер айга озайтылырга мөмкин, әгәр №174-ФЗ Федераль закон белән башкасы каралмаган булса.<br>2. Дәүләт экологик экспертизасын үткәрү срогының башы №174-ФЗ Федераль законның 14 маддәсенең 3 пункты белән билгеләнә.<br>3. Дәүләт экологик экспертизасының Министрлык | №174-ФЗ Федераль законның 14 маддәсе |

| | | |
|---|---|---|
| Федерациясе законнары тарафыннан каралган очракта. | боерыгы белән расланган бәяләмәсе гариза бирүчегә аны раслаган көннән алып өч көн дәвамында җибәрелә.<br>4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында хат җибәрү – гаризаны теркәгән вакыттан алып, шулай ук әлеге Регламентның 2.9 п. белән билгеләнгән срок беткән көннән алып 7 көн.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү срогын туктатып тору каралмаган. | |
| 2.5. Законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе | 1. №174-ФЗ Федераль законның 12 маддәсендә күрсәтелгән объектларның, №174-ФЗ Федераль законның 12 маддәсенең 4.1 пунктчасында күрсәтелгән объектлардан тыш, дәүләт экологик экспертизасын үткәрү, шул исәптән кабатлап үткәрү өчен, гариза бирүче тапшыра:<br>а) дәүләт экологик экспертизасы объекты атамасы турында информацияне эченә алган гариза; дәүләт экологик экспертизасы үткәрүгә гариза бирүче тарафыннан түләүгә счет әзерләү өчен кирәкле реквизитлар (салым түләүченең идентификация номеры (алга таба – ИНН), банк идентификация коды (алга таба – БИК), исәпкә кую сәбәбе коды (алга таба – КПП), предприятие һәм оешмаларның гомумроссия классификаторы коды (алга таба – ОКПО), исәп-хисап счеты, корреспондентлык счеты (алга таба – к/счет); дәүләт экологик экспертизасына тапшырыла торган материалларның әлеге Регламентка 1 кушымтага туры килгән тулы описе; | №174-ФЗ Федераль законның 12,14 маддәләре |

| | | |
|---|---|---|
| | б) №174-ФЗ Федераль законның 12 маддәсе нигезендә дәүләт экологик экспертизасы тиеш булган, каралган тәртиптә билгеләнгән күләмдәге һәм дәүләт экологик экспертизасы тиеш булган хуҗалык һәм бүтән төр эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү материалларын үз эченә алган документация, №174-ФЗ Федераль законның 12 маддәсенең 4.1 пунктчасында күрсәтелгән объектлардан тыш.<br>2. №174-ФЗ Федераль законның 12 маддәсенең 4.1 пунктчасында күрсәтелгән объектларга дәүләт экологик экспертизасы үткәрү, шул исәптән кабатлап үткәрү өчен, гариза бирүче тапшыра:<br>а) дәүләт экологик экспертизасы объекты атамасы турында информацияне эченә алган гариза; дәүләт экологик экспертизасы үткәрүгә гариза бирүче тарафыннан түләүгә счет әзерләү өчен кирәкле реквизитлар (ИНН, БИК, КПП, ОКПО, исәп-хисап счеты, к/счет); дәүләт экологик экспертизасына тапшырыла торган материалларның әлеге Регламентның 1 кушымтасына туры килгән тулы описе;<br>б) дәүләт экологик экспертизасы тиеш булган һәм аеруча саклана торган табигый территорияләр җирләрендә аларны төзү, реконструкцияләү күздә тотыла торган объектларның тиешле аеруча саклана торган табигый территориягә йогынтысын бәяләү материалларын үз эченә алган документация, №174-ФЗ Федераль законның 12 маддәсенең 4.1 пунктчасында күрсәтелгән объектларга дәүләт экологик экспертизасы | |

| | | |
|---|---|---|
| | уздырган очракта;<br>Дәүләт экологик экспертизасы тиеш булган документация ике нөсхәдә тапшырыла, гариза һәм башка материаллар – бер нөсхәдә.<br>Дәүләт хезмәт күрсәтүен алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Министрлыкка (КФҮ, КФҮнең ерактагы эш урынына) шәхсән мөрәҗәгать итеп алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм кушымта итеп бирелә тоган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче зат тарафыннан);<br>почта аша заказлы хат белән, аны тапшыру турында белдереп.<br>Гариза һәм документлар гариза бирүче тарафыннан шулай ук көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, һәм Бердәм Дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәт порталы аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган һәм Дәүләт | 1. №174-ФЗ Федераль законның 12 маддәсенең 4.1 пунктчасында күрсәтелгән объектлардан тыш, №174-ФЗ Федераль законның 12 маддәсендә күрсәтелгән объектларга дәүләт экологик экспертизасы үткәрү | №174-ФЗ Федераль законның 14 маддәсе;<br>№ 210-ФЗ Федераль законның 7 маддәсенең 1 өлешенең 2 пункты; |

| | | |
|---|---|---|
| органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән органнар карамагында торган һәм гариза бирүче аларны тапшыруга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | өчен, Министрлык тарафыннан ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәге документлар алына:<br>а) федераль күзәтчелек һәм контроль органнарының һәм җирле үзидарә органнарының Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә алына торган уңай бәяләмәләре һәм (яки) килешенү документлары;<br>б) федераль башкарма хакимият органнарының дәүләт экологик экспертизасы объекты буенча бәяләмәләре, ул күрсәтелгән башкарма хакимият органары тарафынан каралган очракта, һәм иҗтимагый экологик экспертиза бәяләмәсе, ул үткәрелгән очракта;<br>в) җирле үзидарә органнары тарафыннан оештырылган дәүләт экологик экспертизасы объектын граждannар һәм иҗтимагый оешмалар (берләшмәләр) белән тикшерүләр материаллары.<br>2. №174-ФЗ Федераль законның 12 маддәсенең 4.1 пунктчасында күрсәтелгән объектларга дәүләт экологик экспертизасы үткәрү, шул исәптән кабат үткәрү өчен, Министрлык тарафыннан ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәге документлар алына:<br>а) иҗтимагый экологик экспертиза бәяләмәсе, ул үткәрелгән очракта;<br>б) җирле үзидарә органнары тарафыннан оештырылган дәүләт экологик экспертизасы объектын граждannар һәм иҗтимагый оешмалар (берләшмәләр) белән тикшерүләр материаллары.<br>Гариза бирүче югарыда күрсәтелгән документларны | РФ Хөкүмәтенең № 698 карары |

| | | |
|---|---|---|
| | үзлегеннән тапшырырга хокуклы.<br>Бу пунктта күрсәтелгән документларның гариза бирүче тарафыннан тапшырылмавы дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, норматив хокукый актларда каралган очракларда һәм дәүләт хезмәте күрсәтә торган башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган килешенүләре таләп итәлә торган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәт күрсәтүенең килешенүе таләп ителми | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган комплектын тапшыру.<br>2. Документларның гариза бирүченең мәнфәгатьләрен яклау хокукы вәкаләтләренә ия булмаган зат тарафыннан тапшырылуы. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.<br>Баш тарту өчен нигезләр:<br>1. №174-ФЗ Федераль законның 14 маддәсе һәм РФ Хөкүмәтенең № 822 карары белән билгеләнгән материаллар тапшыру тәртибен бозу. | №174-ФЗ Федераль законның 14 маддәсе;<br>РФ Хөкүмәтенең № 698 карары |

| | | |
|---|---|---|
| | 2. Документация региональ дәрәҗәдәге дәүләт экологик экспертизасы объекты булып тормый.<br>3. Элек тапшырылган материалларның билгеләнгән таләпләргә туры килмәве турында гариза бирүче тарафыннан белдерү кәгазе алынган көннән 30 эш көне узганнан соң дәүләт экологик экспертизасы үткәрү өчен кирәкле материалларны тапшырмау.<br>4. Дәүләт экологик экспертизасы үткәрүгә түләү кирәклеге турында гариза бирүче тарафыннан белдерү кәгазе алынган көннән 30 эш көне узганнан соң дәүләт экологик экспертизасы үткәрүгә түләүне раслый торган документның булмавы.<br>5. Гариза бирүченең эшләп бетерү зарурлыгы дәүләт экологик экспертизасы үткәрү барышында ачыкланган материалларны эшләп бетерүгә кайтару турында гаризасы.<br>6. Гариза бирүченең документацияне дәүләт экологик экспертизасы үткәрмичә кире кайтару турында гаризасы. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки бүтән төр түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте күрсәтү гариза бирүче тарафыннан тулысынча алдан түләү шарты белән гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүгә түләү гариза бирүче тарафыннан акчаларны счетта һәм дәүләт экологик экспертизасын үткәрүгә чыгымнарның Бүлек тарафыннан әзерләнгән сметасында күрсәтелгән күләмдә банк хисабы аша күчерү юлы белән башкарыла. Акчаларны күчерү өчен реквизитлар:<br>Получатель: УФК МФ РФ ПО РТ (МИНЭКОЛОГИИ | №174-ФЗ Федераль закон;<br>РФ Табигать министрлыгының № 205 боерыгы;<br>РФ Табигать министрлыгының № 404 боерыгы |

| | | |
|---|---|---|
| | РТ)<br>ИНН 1659036508<br>КПП 165901001<br>Р/с 40101810800000010001<br>ГРКЦ НБ РТ Банка России г. Казань<br>БИК 049205001<br>ОКТМО 92701000 (Казань)<br>Түләүнең билгеләнеше:<br>КБК – 701 115 07020 01 0000 140 – Дәүләт экологик экспертизасы тиешле һәм аны үткәрү Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган документациянең гариза бирүчесе тарафыннан кертелә торган, дәүләт экологик экспертизасы үткәрүгә чыгымнар сметасы нигезендә исәпләнгән җыемнар.<br>НДС салынмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү бәясен билгеләү №174-ФЗ Федераль законның 28 маддәсе нигезендә, РФ Табигать министрлыгының № 205 боерыгы белән расланган Дәүләт экологик экспертизасы үткәрүгә чыгымнар сметасын билгеләү тәртибенә һәм РФ Табигать министрлыгының № 404 боерыгы белән расланган Дәүләт экологик экспертизасының штататан тыш экспертлары хезмәтенә түләү тәртибенә туры китереп гамәлгә ашырыла | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен алына торган түләү | Зарури һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| тәртибе, күләме һәм нигезләре, андый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп | | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәт күрсәтүләрнең нәтиҗәсен алганда, чиратта көтүнең иң зур срогы | Дәүләт хезмәте күрсәтүгә кәгазь гариза бирү, чират булганда – 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда, чиратта көтүнең иң зур срогы 15 минуттан артырга тиеш түгел.<br>Дәүләт хезмәт күрсәтүгә алучыларның аерым категорияләре өчен чиратлылык билгеләнмәгән. | РФ Президентының 601 номерлы Указы |
| 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы, шул исәптән электрон формада | Гариза һәм документлар кергән көнне | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрнең көтү һәм кабул ителү урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турында законнары нигезендә инвалидларга әлеге объектларга үтү мөмкинлеген тәэмин итүгә таләпләр, мондый хезмәт күрсәтүләр тәртибе турында визуаль, текстлы һәм | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһаз, мәгълүмат стендлары белән җиһазланган биналарда һәм урыннарда гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү урынына инвалидларның каршылыксыз үтү мөмкинлеге (биналарга уңайлы керү-чыгу һәм алар эчендә күчеп йөрү) тәэмин ителә. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарга урнаштырыла, шул исәптән инвалидларның чикле мөмкинлекләрен исәпкә алып. | |

| | | |
|---|---|---|
| мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә таләпләр | | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем ала алырлык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешләре саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәктә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникатив технологияләр кулланып | Дәүләт хезмәтенең һәркем ала алырлык булуы күрсәткечләре булып тора:<br>кабул итү бара торган биналарның җәмәгать транспортына үтү мөмкинлеге булган зонада урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булу;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат стендларында, “Интернет” челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, Министрлыкның рәсми сайтында тулы мәгълүмат булу;<br>гаризаны электрон төрдә бирү мөмкинлеге;<br>гариза бирүче гариза һәм документларны Татарстан Республикасы дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшырган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәтләр порталында шәхси кабинет аша электрон төрдә алу мөмкинлеге (гариза һәм документларны электрон документлар формасында Татарстан Республикасы дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшыру мөмкинлеген тормышка ашырганнан соң);<br>хезмәт күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтеп йөрерлек булуы; | Тәртипнең 2.4 пунктының “п” пунктчасы |

| | | |
|---|---|---|
| | инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтеп йөрерлек булуын тәэмин итү белән бәйле булмаган, аларның башка затлар белән бертигез хезмәт алуына комачаулый торган бүтән төр барьерларны үтүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре булып тора:<br>документларны кабул итү һәм карау срокларын саклау;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу срогын саклау;<br>дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан әлеге Регламентны бозу турында прецедентлар (дәлилләнгән шикаятьләр) булу (прецедентлар, шикаятьләр санының Министрлыкның һәм Министрлык территориаль идарәләренең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затларының гомуми санына мөнәсәбәте);<br>гариза бирүченең белгечләр белән үзара бәйләнешләре саны:<br>гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен турыдан-туры алганда – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпләмичә);<br>гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпләмичә);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны Татарстан Республикасы дәүләт | |

| | | |
|---|---|---|
| | хезмәте һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинет аша җибәргәндә:<br>1. әгәр гариза һәм документларның күчермәләре, № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп электрон имза белән имзаланган (расланган) электрон документлар формасында җибәрелсә – турыдан-туры үзара бәйләнеш таләп ителми;<br>2. әгәр гариза һәм документларның күчермәләре № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп, электрон имза белән имзаланмаган (расланмаган) электрон документлар формасында җибәрелсә – бердән артык түгел.<br>Гариза бирүче белән бер үзара бәйләнешнең дәвамлылыгы – 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан http://www. eco.tatarstan.ru сайтында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында алынырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннары аша башкарылмый. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтүнең үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны һәм сканерланган документларны электрон рәвештә Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрү мөмкинлеге бар, соңыннан документларның оригиналын күрсәтеп. | |

### 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны башкару тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрдә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында башкару үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеге тасвирламасы.

3.1.1. Региональ дәрәҗәдәге объектларга дәүләт экологик экспертизасын (алга таба - дәүләт экологик экспертизасы) оештыру һәм үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үз эченә түбәндәге процедураларны ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2) документларны кабул итү һәм гаризаны теркәү;

3) дәүләт экологик экспертизасын оештыру;

4) дәүләт экологик экспертизасын оештыру һәм үткәрү турында боерык әзерләү һәм чыгару;

5) дәүләт экологик экспертизасын үткәрү;

6) дәүләт экологик экспертизасы бәяләмәсен раслау турында боерык әзерләү һәм чыгару;

7) расланган дәүләт экологик экспертизасы бәяләмәсен бирү.

8) күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтү.

9) техник хатаны төзәтү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы әлеге Регламентка 3нче кушымтада бирелә.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү һәм гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү.

Гариза бирүче, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультация алу өчен, Бүлеккә шәхсән, почта буенча, телефон буенча, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (фунцияләр) порталы аша һәм (яки) электрон почта ярдәмендә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән гаризаның формасы буенча һәм дәүләт хезмәт күрсәтүен алу өчен башка сораулар буенча. Кирәк булганда, Бүлек белгече гариза бирүчегә ярдәм итә, шул исәптән дәүләт хезмәт күрсәтүе өчен кирәкле гаризаны рәсмиләштерү өлешендә.

Бу пункт белән билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гаризаның формасы буенча һәм дәүләт хезмәт күрсәтүен алу өчен башка сораулар буенча консультация, шулай ук гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү.

3.3. Документларны кабул итү һәм гаризаны теркәү.

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән яки вәкиле аша, Административ регламентның 2.5 пунктының 1 пунктчасы нигезендә материалларны кушымтада теркәп, Министрлыкка

дәүләт хезмәт күрсәтүенә гариза яза, аның эчтәлеге бу Административ регламент таләпләренә туры килергә тиеш. Гариза бирүче шулай ук дәүләт хезмәт күрсәтүе турында гаризаны электрон төрдә Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталы аша бирергә хокуклы.

Гариза бирүченең вәкиленең вәкаләтләре билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән булырга тиеш.

Аларны төзү, реконструкцияләүне аеруча саклана торган табигый территорияләр җирләрендә гамәлгә ашыру күздә тотыла торган объектларның проект документларына дәүләт экологик экспертизасы үткәрү өчен, бу Административ регламентның 2.5 пунктының 2 пунктчасында каралган документлар гариза бирүче тарафыннан РФ Хөкүмәтенең 822 номерлы карары белән расланган Төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлауны аеруча саклана торган табигый территорияләр җирләрендә гамәлгә ашыру күздә тотыла торган объектларның проект документациясен дәүләт экспертизасы һәм дәүләт экологик экспертизасы үткәрү өчен тапшыру кагыйдәләре белән билгеләнгән тәртиптә тапшырыла.

3.3.2. Министрлыкның документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге белгече гамәлгә ашыра:

гаризаны һәм аңа кушымта итеп бирелә торган документларны кабул итү һәм теркәү;

гаризаны һәм документларны документларны кабул итүдән баш тарту өчен бу Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булуга тикшерү. Тикшерү Бүлек белгече катнашында башкарыла.

Гариза бирүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, документларны кабул итүдән баш тарту өчен бу Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булган очракта, Бүлек Белгече гариза бирүчегә документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту өчен нигезләр булуы турында хәбәр итә һәм, баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, документларны аңа кире кайтара. Гариза бирүченең таләбе буенча баш тарту язма рәвештә рәсмиләштерелә.

Гариза бирүче тарафыннан гариза һәм документлар почта аша җибәрелгәндә, Бүлек белгече, баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны аңа почта аша кире кайтара.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен бу Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, гаризаны һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының “Электрон Хөкүмәт” бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасында (алга таба – Электрон документ әйләнеше) терки.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән һәм Министрга җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.3. Министр гаризаны карый һәм министрың беренче урынбасарына карау өчен җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министрның беренче урынбасарына карау өчен җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.4. Министрның беренче урынбасары гаризаны карый һәм Дәүләт экологик экспертизасы һәм әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны нормалаштыру идарәсе башлыгына (алга таба – Идарә башлыгы) карау өчен җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Идарә башлыгына карау өчен җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.5. Идарә башлыгы гаризаны карый һәм Бүлек башлыгына карау өчен җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына карау өчен җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.6. Бүлек башлыгы дәүләт хезмәте күрсәтү буенча җаваплы башкаручыны билгеләп куя.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.4. Дәүләт экологик экспертизасын оештыру.

3.4.1. Җаваплы башкаручы, теркәлгән документларны алгач, түбәндәге оештыру чараларын гамәлгә ашыра:

материалларны дәүләт экологик экспертизасына тапшыру тәртибенә туры килүне тикшерү;

документацияне региональ дәрәҗәдәге дәүләт экологик экспертизасы объектлары исемлегенә туры килүен билгеләү өчен тикшерү;

документларның комплектлыгын тикшерү, шул исәптән документация составында хуҗалык яки бүтән төр эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү материаллары булуын;

әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны ведомствоара хезмәттәшлек системасы кысаларында тиешле дәүләт органнарыннан сората (алар гариза бирүче тарафыннан үз инициативасы буенча тапшырылмаган очракта).

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура, аннан алдагы процедура тәмамланган вакыттан алып 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: анализланган документлар һәм ведомствоара хезмәттәшлек системасы кысаларында тиешле дәүләт органнарына җибәрелгән запрослар.

3.4.2. Мәгълүматлар бирүчеләрнең белгечләре ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән, 3.4.1 пунктта күрсәтелгән запрос нигезендә соратылган документларны (мәгълүматларны) билгеләнгән срокта бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура, аннан алдагы процедура тәмамланган вакыттан алып 3 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Соратылган мәгълүматларның булмавы дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

Процедураның нәтиҗәсе: алынган документлар (мәгълүматлар) яисә баш тарту турында Министрлыкка җибәрелгән белдерү кәгазьләре.

3.4.3. Җаваплы башкаручы, 2.9 пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән

нигезләр булганда, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын әзерли һәм Бүлек башлыгына (ул юк чакта – Бүлек башлыгы вазыйфаларын башкаручыга) җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура, 3.4.1 пунктта күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан алып 5 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килешендерү өчен җибәрелгән Министрлык белдерүе кәгазе проекты.

3.4.4. Бүлек башлыгы Министрлык белдерүе кәгазе проектын килешендерә һәм аны, килешендерү өчен, Идарә башлыгына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар бу Регламентның 3.4.3. пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан алып 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгы тарафыннан килешендерелгән һәм килешендерүгә Идарә башлыгына җибәрелгән Министрлык белдерүе кәгазе проекты.

3.4.5. Идарә башлыгы (ул юк чакта - Идарә башлыгы вазыйфаларын башкаручы) Министрлык белдерүе кәгазе проектын килешендерә һәм аны, имзалау өчен, Министрның беренче урынбасарына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар бу Регламентның 3.4.3. пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан алып 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Идарә башлыгы тарафыннан килешендерелгән һәм имзалау өчен, Министрның беренче урынбасарына җибәрелгән Министрлык белдерүе кәгазе проекты.

3.4.6. Министрның беренче урынбасары (ул юк чакта - министр вазыйфаларын башкаручы зат) Министрлык белдерүе кәгазенә имза куя.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар, бу Регламентның 3.4.3. пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан алып 2 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында имза куелган Министрлык белдерүе кәгазе.

3.4.7. Җаваплы башкаручы, материалларның комплекты җитмәвен ачыклаганда, шул исәптән хуҗалык яки бүтән төр эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү материаллары, дәүләт экологик экспертизасы объекты буенча гражданнар һәм иҗтимагый оешмалар (берләшмәләр) белән җирле үзидарә органнары тарафыннан оештырылган фикер алышу материаллары булмаганда, белдерү алган көннән алып 30 көн дәвамында материалларны комплектлаштырып җиткерү кирәклеге турында белдерү проекты әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар, бу Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан алып 5 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килешендерү өчен җибәрелгән Министрлык белдерүе проекты.

3.4.8. Бүлек башлыгы Министрлык белдерүе проектын килешендерә һәм аны, килешендерү өчен, Идарә башлыгына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар, бу Регламентның 3.4.7. пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан алып 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгы тарафыннан килешендерелгән һәм килешендерүгә Идарә башлыгына җибәрелгән Министрлык белдерүе кәгазе проекты.

3.4.9. Идарә башлыгы (ул юк чакта - Идарә башлыгы вазыйфаларын башкаручы) Министрлык белдерүе проектын килешендерә һәм аны, имзалау өчен, Министрның беренче урынбасарына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар, бу Регламентның 3.4.7. пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан алып 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Идарә башлыгы тарафыннан килешендерелгән һәм имзалау өчен, Министрның беренче урынбасарына җибәрелгән Министрлык белдерүе кәгазе проекты.

3.4.10. Министрның беренче урынбасары (ул юк чакта - министр вазыйфаларын башкаручы зат) Министрлык белдерүе кәгазенә имза куя.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар, бу Регламентның 3.4.7. пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан алып 2 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: 30 календарь көн дәвамында материалларны комплектлаштырып бетерү зарурлыгы турында имзаланган Министрлык белдерүе кәгазе.

3.4.11. Җаваплы башкаручы, 2.9 пунктның 3 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр булганда, 3.4.3.- 3.4.6 пунктлар белән билгеләнгән процедураларны гамәлгә ашыра.

3.4.12. Җаваплы башкаручы, 2.9 пунктның 1-3 пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр булмаганда гамәлгә ашыра:

дәүләт экологик экспертизасы үткәрүгә чыгымнар сметасы әзерләү;

гариза бирүче адресына тиешле белдерү кәгазен әзерләү.

Дәүләт экологик экспертизасы үткәрүгә смета нигезендә Министрлыкның финанс контроле, исәп һәм хисаплылык бүлеге тарафыннан дәүләт экологик экспертизасы үткәрү өчен җыемны түләүгә счет һәм банк реквизитлары рәсмиләштерелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар, бу Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан алып 5 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килешендерү өчен җибәрелгән Министрлык белдерүе кәгазе проекты.

3.4.13. Бүлек башлыгы Министрлык белдерүе кәгазе проектын килешендерә һәм аны, килешендерү өчен, Идарә башлыгына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар, әлеге Регламентның 3.4.12. пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан алып 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгы тарафыннан килешендерелгән һәм килешендерү өчен Идарә башлыгына җибәрелгән Министрлык белдерүе кәгазе проекты.

3.4.14. Идарә башлыгы (ул юк чакта - Идарә башлыгы вазыйфаларын башкаручы) Министрлык белдерүе кәгазе проектын килешендерә һәм аны, имзалау өчен, Министрның беренче урынбасарына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар, әлеге Регламентның 3.4.12. пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан алып 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Идарә башлыгы тарафыннан килешендерелгән һәм имза кую өчен, Министрның беренче урынбасарына җибәрелгән Министрлык белдерүе кәгазе проекты.

3.4.15. Министрның беренче урынбасары (ул юк чакта - министр вазыйфаларын башкаручы зат) Министрлык белдерүе кәгазенә имза куя.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.4.12. пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан алып 2 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: материалларның комплектлылыгы һәм Дәүләт экологик экспертизасы үткәрүгә 30 календарь көн эчендә түләргә кирәклеге турында имзаланган Министрлык белдерүе кәгазе, смета һәм түләү өчен исәпне теркәп биреп.

3.4.16. Җаваплы башкаручы, 2.9 пунктның 4 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр булганда, 3.4.3.- 3.4.6.пунктлар белән билгеләнгән процедураларны гамәлгә ашыра.

### 3.5. Дәүләт экологик экспертизасы үткәрү турында боерык әзерләү һәм чыгару.

3.5.1. Министрлыкка Дәүләт экологик экспертизасы үткәрүгә түләүне раслый торган документ кергәч, эксперт комиссиясенең җаваплы сәркатибе дә булып тора торган җаваплы башкаручы дәүләт экологик экспертизасын оештыру һәм үткәрү турында эксперт комиссиясенең составын (җитәкче, җаваплы сәркатип һәм эксперт комиссиясе әгъзалары), дәүләт экологик экспертизасын үткәрү срогын, дәүләт экологик экспертизасы үткәрүгә заданиене билгели торган боерык проектын әзерли.

Идарә башлыгы, Бүлек башлыгы, җаваплы сәркатип җитәкче кандидатуралары буенча, ә аннан соң җитәкченең тәкъдимнәре катнашында эксперт комиссиясе әгъзалары кандидатуралары буенча, шулай ук дәүләт экологик экспертизасын үткәрү сроклары буенча тәкъдимнәр әзерләүне гамәлгә ашыралар.

Эксперт комиссиясе әгъзалары саны так булырга һәм, җитәкчедән һәм җаваплы сәркатиптән тыш, өчтән ким булмаган кеше тәшкил итәргә тиеш. Эксперт комиссиясе әгъзалары Министрлыкның штаттагы хезмәткәрләре арасыннан һәм региональ дәрәҗәдәге дәүләт экологик экспертизасы үткәргәндә җәлеп итү өчен штаттан тыш экспертлардан билгеләнә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар, дәүләт экологик экспертизасын үткәрүгә түләүне раслый торган документ кергән вакыттан алып 13 эш көненнән соңга калмыйча, ә № 174-ФЗ Федераль законның 12 маддәсенең 4.1 пунктында күрсәтелгән объектларга мөнәсәбәттә 1 эш көненнән соң соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килешендерү өчен җибәрелгән Министрлык боерыгы проекты..

3.5.2. Бүлек башлыгы Министрлык боерыгы проектын килешендерә һәм аны килешендерүгә Идарә башлыгына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар, әлеге Регламентның 3.5.1. пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан алып 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгы тарафыннан килешендерелгән һәм килешендерү өчен Идарә башлыгына, хокукый тәэминат бүлеге башлыгына, финанс контроле һәм хисаплылык бүлеге башлыгына җибәрелгән Министрлык боерыгы проекты.

3.5.3. Идарә башлыгы (ул юк чакта - Идарә башлыгы вазыйфаларын башкаручы), хокукый тәэминат бүлеге башлыгы (ул юк чакта - бүлек башлыгы вазыйфаларын башкаручы), финанс контроле һәм хисаплылык бүлеге башлыгы (ул юк чакта - бүлек башлыгы вазыйфаларын башкаручы) Министрлык боерыгы проектын килешендерәләр һәм аны килешендерүгә Министрның беренче урынбасарына җибәрәләр.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.5.1. пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан алып 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Идарә башлыгы белән, хокукый тәэминат бүлеге башлыгы белән, финанс контроле һәм хисаплылык бүлеге башлыгы белән килешендерелгән һәм Министрның беренче урынбасарына килешендерүгә җибәрелгән Министрлык боерыгы проекты.

3.5.4. Министрның беренче урынбасары (ул юк чакта - министр вазыйфаларын башкаручы зат) Министрлык боерыгы проектын килешендерә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.5.1. пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан алып 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла..

Процедураның нәтиҗәсе: Министрның беренче урынбасары тарафыннан килешендерелгән һәм раслау өчен Министрга җибәрелгән Министрлык боерыгы проекты.

3.5.5. Министр (ул юк чакта - министр вазыйфаларын башкаручы зат) дәүләт экологик экспертизасын оештыру һәм үткәрү турында эксперт комиссиясенең составын (җитәкче, җаваплы сәркатип һәм эксперт комиссиясе әгъзалары), дәүләт экологик экспертизасын үткәрү срогын, дәүләт экологик экспертизасы үткәрүгә заданиене билгели торган боерык проектын раслый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.5.1. пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан алып 2 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Министрлыкның расланган боерыгы

3.6. Дәүләт экологик экспертизасы үткәрү.

3.6.1. Җаваплы сәркатип дәүләт экологик экспертизасын оештыру һәм үткәрү турында боерыкны раслау нәтиҗәләре буенча эксперт комиссиясе эшен оештыра.

Эксперт комиссиясенең эше оештыру утырышы үткәрүдән башлана, анда эксперт комиссиясе җитәкчесе, җаваплы сәркатип, эксперт комиссиясе әгъзалары, гариза бирүче яки аның вәкилләре, шулай ук, кирәк булганда, бүтән кызыксынулы якларның вәкилләре катнаша.

Эксперт комиссиясенең оештыру утырышы дәүләт экспертизасы үткәрү турында боерык чыкканнан алып 5 эш көненнән артмаган срокта үткәрелә. Җаваплы сәркатип гариза бирүчегә оештыру утырышын үткәрү датасы һәм урыны турында почта аша җибәреп, телефонограмма белән яки гомуми кулланылыштагы мәгълүмат системаларын файдаланып җибәрелгән хәбәр аша белдерә. Бүтән кызыксынулы якларның (Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалар) вәкилләре эксперт комиссиясенең оештыру утырышын үткәрү датасы һәм урыны турында белдерүне утырышта катнашуга билгеләнгән тәртиптә язмача запрослары булган очракта алалар.

Оештыру утырышы барышында:

җаваплы сәркатип дәүләт экспертизасы оештыру һәм үткәрү турында боерык хакында хәбәр итә;

эксперт комиссиясе җитәкчесе дәүләт экспертизасын үткәрү тәртибе турында информация бирә;

гариза бирүче яки аның вәкилләре ниятләнелгән эшчәнлек характеры турында доклад ясыйлар;

эксперт комиссиясе җитәкчесе һәм эксперт комиссиясе әгъзалары тарафыннан (Министрлыкның штаттагы хезмәткәрләреннән тыш) документлар карау, эксперт бәяләмәләре әзерләү буенча түләүле эш (хезмәт) күрсәтүгә договорларга кул куела;

эксперт комиссиясенең, эксперт төркемнәренең (аларны оештырганда) һәм экспертлар эшенең календарь планы аныклана;

төркемле (эксперт төркемнәре булганда) һәм индивидуаль эксперт бәяләмәләрен әзерләү сроклары билгеләнә;

эксперт комиссиясе бәяләмәсе проектын әзерләү срогы билгеләнә;

дәүләт экспертизасы объекты булып торган документларны эксперт комиссиясе әгъзаларына тапшыру гамәлгә ашырыла.

Дәүләт экологик экспертизасы объекты турында, аны һәрьяклап һәм объектив бәяләү максатында, дәүләт экологик экспертизасы эксперт комиссиясе әгъзалары гаризасы нигезендә зарури булганда, өстәмә мәгълүмат алу өчен, җаваплы сәркатип тарафыннан гариза бирүче адресына тиешле белдерү хаты җибәрелә.

Дәүләт экологик экспертизасы объекты турында өстәмә мәгълүмат тапшыру зарурлыгы турында белдерү хаты проекты җаваплы сәркатип тарафыннан дәүләт экологик экспертизасы эксперт комиссиясе әгъзаларыннан тиешле гариза кергән көннән алып 3 эш көненнән артмаган срокта әзерләнә, килешендерү өчен бүлек башлыгына, идарә башлыгына һәм имзалау өчен министрның беренче урынбасарына тапшырыла.

Гариза бирүчедән кергән өстәмә материаллар гаризаны теркәү тәртибендә теркәлә һәм, эксперт комиссиясе эшендә файдалану өчен, җаваплы сәркатипкә тапшырыла. Гариза бирүче тарафыннан өстәмә материаллар тапшырылмаган очракта, экспертлар тарафыннан дәүләт экологик экспертизасы объекты булып торган документация баштагы күләмендә карала.

Дәүләт экологик экспертизасы объекты турында өстәмә информация алу өчен кирәк булган очракта, эксперт комиссиясе әгъзаларының ниятләнелә торган эшчәнлек урынына чыгуы оештырылырга мөмкин.

Эксперт комиссиясе эше процессында:

индивидуаль һәм төркемле (эксперт төркемнәре булганда) эксперт бәяләмәләре әзерләнә, алар эксперт комиссиясенең җаваплы сәркатибенә тапшырыла;

эксперт комиссиясе утырышлары уздырыла, шул исәптән, №174-ФЗ Федераль законның 26 маддәсе белән каралган хокукларны гамәлгә ашыру максатында, гариза бирүче һәм/яки аның вәкилләре катнашында;

эксперт комиссиясе утырышларында индивидуаль һәм төркемле (эксперт төркемнәре булганда) эксперт бәяләмәләре карала;

эксперт комиссиясе җитәкчесе һәм җаваплы сәркатибе тарафыннан индивидуаль һәм төркемле эксперт бәяләмәләре нигезендә эксперт комиссиясе бәяләмәсенең проекты төзелә.

Эксперт комиссиясе утырышлары эксперт комиссиясе җитәкчесе һәм җаваплы

сәркатибе тарафыннан кул куела торган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.

Эксперт комиссиясенең гариза бирүче һәм/яки аның вәкилләре, шулай ук бүтән кызыксынулы якларның (Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалар) вәкилләре катнашырга мөмкин булган йомгаклау утырышында:

эксперт комиссиясе бәяләмәсенең проекты тикшерелә;

эксперт комиссиясе җитәкчесе эксперт комиссиясе эше нәтиҗәләре һәм бәяләмә проекты йомгаклары турында доклад ясый;

бәяләмә проектына эксперт комиссиясе җитәкчесе, аның җаваплы сәркатибе һәм комиссиянең бөтен әгъзалары тарафыннан имза куела;

эксперт комиссиясе җитәкчесе һәм әгъзалары (Министрлыкның штаттагы хезмәткәрләреннән тыш) башкарылган эшләрне кабул итү актына кул куялар.

Эксперт комиссиясенең аның җитәкчесе һәм җаваплы сәркатибе тарафыннан әзерләнгән җыелма бәяләмәсе проекты эксперт комиссиясе исемлек составының квалификацияле күпчелеге (өчтән ике өлештән ким түгел) тарафыннан хупланган очракта, бәяләмә проекты эксперт комиссиясе әгъзаларының тулы составы тарафыннан имзалана, аннан соң ул эксперт комиссиясе тарафыннан әзерләнгән бәяләмә булып тора.

Эксперт комиссиясе тарафыннан әзерләнгән бәяләмә аңа имза куйган затлар ризалыгыннан башка үзгәртелә алмый.

Эксперт комиссиясенең аерым әгъзалары эксперт комиссиясе тарафыннан әзерләнгән бәяләмә белән килешмәгән очракта, алар бәяләмәгә “аерым фикер” тамгасы белән имза куялар. Эксперт тарафыннан аерым фикер экспертның бәяләмә йомгаклары белән килешмәү сәбәпләрен нигезләүне һәм экспертизага тапшырылган материалларның техник регламентларга һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә законнарга туры китереп билгеләнгән экологик таләпләргә һәм нормаларга туры килмәвенең конкрет фактларын эченә алган документ рәвешендә рәсмиләштерелә.

Эксперт комиссиясе тарафыннан әзерләнгән уңай бәяләмә үз эченә түбәндәге нәтиҗәләрне алырга тиеш:

дәүләт экспертизасы объектын гамәлгә ашыру белән бәйле рәвештә ниятләнелә торган хуҗалык һәм бүтән төр эшчәнлекне нигезли торган документларның һәм/яки документациянең техник регламентларга һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә законнарга туры китереп билгеләнгән экологик таләпләргә туры килүе турында;

экспертиза объектын гамәлгә ашыру мөмкинлеге турында.

Эксперт комиссиясе тарафыннан әзерләнгән тискәре бәяләмә үз эченә ике төрдәге нәтиҗәләрне алырга мөмкин:

а) тапшырылаган документларны эксперт комиссиясе тарафыннан әзерләнгән бәяләмәдә бәян ителгән күрсәтмәләр һәм тәкъдимнәр буенча эшләп бетерү зарурлыгы турында;

б) ниятләнелә торган эшчәнлекнең экологик иминлек таләпләрен саклауны тәэмин итмәве сәбәпле, экспертиза объектын гамәлгә ашыру ярамавы турында.

Эксперт комиссиясе тарафыннан әзерләнгән бәяләмә, экспертларның аерым фикерләре белән, ике нөсхәдә һәм эксперт комиссиясенең йомгаклау утырышының беркетмәсе Министрлыкның вәкаләтле бүлекчәсенә (бүлегенә) бәяләмәне раслау турында боерык проектын әзерләү өчен тапшырылалар.

Эксперт комиссиясе исемлеге составының өчтән береннән күбрәге җыелма бәяләмә проекты нәтиҗәләре белән килешмәгәндә, комиссия җитәкчесе бүлек

башлыгы һәм идарә башлыгы белән берлектә министрның беренче урынбасарына һәм министрга гамәлдәге составта комиссия тарафыннан карар кабул итү мөмкин түгеллеге, дәүләт экспертизасы үткәрү срогын озайту зарурлыгы һәм комиссия составына экспертлар өстәп кертү турында доклад ясыйлар. Дәүләт экспертизасы үткәрү срогын озайту зарурлыгы һәм комиссия составына экспертлар өстәп кертү турында карар Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә.

Дәүләт экологик экспертизасы эксперт комиссиясе бәяләмәсенә имзалар куйганнан соң, җаваплы сәркатип 3 эш көне дәвамында эксперт комиссиясе җитәкчесе һәм әгъзалары белән түләүле эш (хезмәт) күрсәтүгә билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән договорларны һәм эксперт комиссиясе җитәкчесе һәм әгъзалары тарафыннан башкарылган эшләрне кабул итү актларын Министрлыкның финанс контроле, исәп һәм хисаплылык бүлегенә күрсәтелгән эшләргә (хезмәтләргә) түләү өчен җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.5. пунктында күрсәтелгән Министрлык боерыгы белән билгеләнгән, өч айдан арта алмый торган һәм заказчы гаризасы буенча бер айга озайтылырга мөмкин булган срок дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт экологик экспертизасы бүлегенә тапшырылган дәүләт экологик экспертизасы эксперт комиссиясенең җыелма бәяләмәсе (уңай яки тискәре).

3.6.2. Җаваплы сәркатип, 2.9. пунктның 5 һәм 6 пунктчалары буенча нигезләр булганда, Регламентның 3.4.3-3.4.6 пунктлары белән билгеләнгән процедураларны гамәлгә ашыра.

3.7. Дәүләт экологик экспертизасы бәяләмәсен раслау турында боерык әзерләү һәм чыгару.

3.7.1. Җавалы сәркатип тарафыннан 3.6.1. пункт белән билгеләнгән процедура нәтиҗәләре буенча эксперт комиссиясе тарафыннан әзерләнгән бәяләмәне раслау турында боерык проекты әзерләнә һәм, килешендерү өчен, Бүлек башлыгына җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура 3.6.1. пункт процедурасы тәмамланган вакыттан алып 3 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килешендерү өчен җибәрелгән Министрлык боерыгы проекты.

3.7.2. Бүлек башлыгы Министрлык боерыгы проектын килешендерә һәм аны килешендерүгә Идарә башлыгына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.7.1. пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан алып 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгы тарафыннан килешендерелгән һәм килешендерү өчен Идарә башлыгына, хокукый тәэминат бүлеге башлыгына, финанс контроле һәм хисаплылыгы бүлеге башлыгына җибәрелгән Министрлык боерыгы проекты.

3.7.3. Идарә башлыгы, хокукый тәэминат бүлеге башлыгы (ул юк чакта - бүлек башлыгы вазыйфаларын башкаручы), финанс контроле һәм хисаплылык бүлеге башлыгы (ул юк чакта - бүлек башлыгы вазыйфаларын башкаручы) Министрлык боерыгы проектын килешендерәләр һәм аны Министрның беренче урынбасарына килешендерү өчен җибәрәләр.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.7.1. пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан алып 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Идарә башлыгы, хокукый тәэминат бүлеге башлыгы, финанс контроле һәм хисаплылык бүлеге башлыгы тарафыннан килешендерелгән һәм Министрның беренче урынбасарына килешендерү өчен җибәрелгән Министрлык боерыгы проекты.

3.7.4. Министрның беренче урынбасары (ул юк чакта - министр вазыйфаларын башкаручы зат) Министрлык боерыгы проектын килешендерә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.7.1. пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан алып 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрның беренче урынбасары тарафыннан килешендерелгән һәм Министрга раслау өчен җибәрелгән Министрлык боерыгы проекты.

3.7.5. Министр (ул юк чакта - министр вазыйфаларын башкаручы зат) дәүләт экологик экспертизасы эксперт комиссиясенең бәяләмәсен раслау турында Министрлык боерыгы проектын раслый.

Эксперт комиссиясе тарафыннан әзерләнгән бәяләмә Министрлык боерыгы белән расланганнан соң, Дәүләт экспертизасы тәмамланган санала.

Эксперт комиссиясе тарафыннан әзерләнгән бәяләмә аны раслаган көннән дәүләт экспертизасы бәяләмәсе статусы ала.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.7.1. пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан алып 2 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкның расланган боерыгы.

3.8. Дәүләт экологик экспертизасының расланган бәяләмәсен бирү.

3.8.1. Җаваплы сәркатип 3.7. пункт белән билгеләнгән процедуралар нәтиҗәсе буенча белдерү хатлары проектларын түбәндәгеләрнең адресына әзерли:

гариза бирүчегә, дәүләт экологик экспертизасының тәмамлануы һәм дәүләт экологик экспертизасы бәяләмәсе җибәрелү турында;

Министрлыкның территориаль идарәләренә;

җирле үзидарә органнарына һәм экологик экспертиза өлкәсендә федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан билгеләнә торган очракларда;

- дәүләт экспертизасы объектын гамәлгә ашыруны финанслауны башкара торган кредит оешмаларына.

Министрлыкның дәүләт экологик экспертизасы бүлеге мәгълүматны Министрлыкның “Интернет” челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны, дәүләт экспертизасы үткәрү нәтиҗәләре турында белдерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт экспертизасына тапшырылган документларның бер нөсхәсе, экспертиза тәмамланганнан соң, Министрлык архивында саклау өчен формалаштырыла, калган документлар гариза бирүчегә кайтарыла. Документларны архивта саклау срогы әйләнә-тирә мохиткә әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнарны бозып китерелгән зыянны компенсацияләү турында дәгъва белдерү срогы белән билгеләнә һәм егерме ел тәшкил итә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура 3.7 пунктта күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан алып 5 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килешендерүгә җибәрелгән Министрлык белдерүләре проектлары.

3.8.2. Бүлек башлыгы Министрлык белдерүләре проектларын килешендерә һәм, килешендерү өчен, Идарә башлыгына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.8.1. пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан алып 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгы тарафыннан килешендерелгән һәм Идарә башлыгына килешендерүгә җибәрелгән Министрлык белдерүләре проектлары.

3.8.3. Идарә башлыгы (ул юк чакта - Идарә башлыгы вазыйфаларын башкаручы) Министрлык белдерүләре проектларын килешендерә һәм аларны Министрның беренче урынбасарына имзалауга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.8.1. пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан алып 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Идарә башлыгы тарафыннан килешендерелгән һәм Министрның беренче урынбасарына имзалауга җибәрелгән Министрлык белдерүләре проектлары.

3.8.4. Министрның беренче урынбасары (ул юк чакта - министр вазыйфаларын башкаручы зат) Министрлык белдерүенә имза куя.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.8.1. пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланган вакыттан алып 2 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: имза куелган Министрлык белдерүләре.

3.9. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша күрсәтү мөмкинлеге.

Дәүләт хезмәте күрсәтү дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннары аша гамәлгә ашырылмый.

3.10. Техник хаталарны (ялгыш язу, басма хата, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

3.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата (ялгыш язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата) табылган очракта, гариза бирүче Министрлыкка тапшыра:

техник хатаны (ялгыш язу, басма хата, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза (кушымта 2);

гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы (язма хата, басма хата, грамматик яки арифметик хата) булган документ;

техник хата (ялгыш язулар, басма хаталар, грамматик яки арифметик хата) барлыгын исбатлый торган, юридик көчкә ия булган документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән мәгълүматларда техник хатаны (ялгыш язулар, басма хаталарны, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза гариза бирүче (вәкаләтле вәкиле)

тарафыннан шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән, электрон почтаны файдаланып) җибәреп, яисә бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшырыла.

3.10.2. Министрлыкның документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге белгече техник хатаны (ялгыш язулар, басма хаталарны, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гаризаны кушымта итеп бирелгән документлары белән кабул итүне гамәлгә ашыра һәм гаризаны электрон бердәм ведомствоара документ әйләнеше системасы аша терки.

Бу пунктча белән билгеләнә торган процедура гариза кергән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карауга җибәрелгән гариза.

3.10.3. Бүлек белгече документларны карый һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтүләр кертү максатында, төзәтелгән документны гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкиленә) шәхсән кул куйдырып тапшыра, гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкиленнән) техник хата (ялгыш язулар, басма хаталар, грамматик яки арифметик хата) булган документның оригиналын алып кала, яки гариза бирүче адресына документны Министрлыкка техник хата (ялгыш язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата) булган документның оригиналын тапшырганда алу мөмкинлеге турында почта аша (электрон почта ярдәмендә) хат җибәрә.

Бу пунктча белән билгеләнә торган процедура техник хата (ялгыш язулар, басма хаталар, грамматик яки арифметик хата) табылганнан соң яки җибәрелгән хата (ялгыш язулар, басма хаталар, грамматик яки арифметик хата) турында теләсә кайсы кызыксынулы заттан гариза алганнан соң 3 көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту үз эченә ала: гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерү, шикаятьләр карау, тикшерүләр үткәрү, карарлар кабул итү һәм гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләренә җаваплар әзерләү, Министрлыкның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләү.

Административ процедураларның үтәлешен саклауны контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документлар проектларына экспертиза үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;
- эш башкаруның алып барылышына билгеләнгән тәртиптә тикшерү үткәрү;
- билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Планлы тикшерүләр Министрлыкның ярты еллык һәм еллык планнары нигезендә гамәлгә ашырыла. Планнан тыш тикшерүләр гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча үткәрелә.

Әлеге Регламентның 3 бүлеге белән билгеләнгән административ процедураларны башкаруны контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатларында, дәүләт хезмәте күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә, министрга дәүләт хезмәте күрсәтү

нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча аерым административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген саклауга агымдагы контроль Бүлек башлыгы тарафыннан башкарыла.

4.3. Әлеге Регламентның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыра торган вазыйфаи затлар исемлеге Министрлык бүлекләре турында нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Күрсәтелгән контрольне гамәлгә ашыру периодлары министр тарафыннан билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җавапка тартыла.

4.4. Министр (министрның беренче урынбасары) гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен вакытында карауны контрольдә тота.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан контроль Министрлык эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыклыгы юлы белән, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында актуаль һәм төгәл мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге белән гамәлгә ашырыла.

## 5. Гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтә торган Министрлыкның, шулай ук аның дәүләт хезмәте күрсәтә торган вазыйфаи затының, яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә Министрлыкның дәүләт хезмәткәренең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр тәртиптә – Министрлыкка шикаять бирү хокукына ия. Дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле рәвештә министр карарларынаа, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән, түбәндәге очракларда:

1) гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризасын теркәү срогын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогын бозу;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән каралмаган документлар таләп итү;

4) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен аларны тапшыру Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән федераль законнар һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән каралмаган нигезләрдә баш тарту;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә, гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән каралмаган түләү таләп итү;

7) Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу.

5.2. Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, Министрлыкның рәсми сайтын, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталын, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталын файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү вакытында алынырга мөмкин.

5.3. Дәүләт хезмәт күрсәтүе алучыларның шикаяте үз эченә түбәндәге мәгълүматны алырга тиеш:

карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) шикаятьләнә торган Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең атамасы;

гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүматлар яисә гариза бирүче юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында мәгълүматлар, шулай ук контакт телефоны номеры (номерлары), гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле электрон почта (булган очракта) адресы (адреслары) һәм почта адресы;

Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең шикаятьләнә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүматлар;

Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән гариза бирүченең килешмәвенә нигез булып торган дәлилләр.

5.4. Министрлыкка кергән шикаять аны теркәгән көннән алып 15 эш көне дәвамында шикаятьләрне карау вәкаләтләренә ия булган вазыйфаи зат тарафыннан каралырга тиеш, ә Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының гариза бирүчедән документларны алудан баш тартуы яисә җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелү очрагында яки андый хаталарны төзәтү срогын бозуга шикаять белдерелү очрагында - аны теркәгән көннән алып 5 эш көне дәвамында.

Гариза бирүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яисә аларның күчермәләре тапшырыларга мөмкин.

5.5. Шикаять гариза бирүче тарафыннан шәхсән яисә аның вәкаләтле заты тарафыннан имзалана.

5.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда Министрлык тарафыннан җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтү, аларны түләтү Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән, Татарстан Республикасы норматив

хокукый актлары белән каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару формасында, шулай ук бүтән формаларда;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Гариза бирүчегә, бу пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча, шикаятьне карау нәтиҗәләре турында язмача формада һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон формада дәлилле җавап җибәрелә.

5.7. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре расланган очракта, шикаятьләрне карау буенча вәкаләтләргә ия булган вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Региональ дәрәҗәдәге объектларга дәүләт экологик экспертизасы оештыру һәм үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына
Кушымта 1

ГАРИЗАНЫҢ ТӘКЪДИМ ИТЕЛӘ ТОРГАН ФОРМАСЫ

ГАРИЗА

Дәүләт экологик экспертизасы оештыру һәм үткәрү өчен материаллар җибәрәбез:

_______________________________________________________________

(дәүләт экологик экспертизасы объекты исеме)

Кушымта: дәүләт экологик экспертизасына тапшырыла торган материалларның төгәл описе __биттә, __нөсхәдә.

Гаризада һәм кушымта итеп бирелә торган документларда күрсәтелгән мәгълүматның хаклыгын һәм тулылыгын раслыйм.

Җитәкче ____________________________ _____________ ______________

(оешма атамасы) (имза) (Ф.И.О.)

М.У. (булган очракта)

___________________

(дата)

Элемтәләр өчен телефон/факс/E-mail:____________________________________

Региональ дәрәҗәдәге объектларга
дәүләт экологик экспертизасы оештыру
һәм үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
Административ регламентына
Кушымта 2

Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министрына

________________________________________

______________________________________-дан

физик затлар, шәхси эшмәкәрләр өчен:
Ф.И.О.,адрес (почта һәм(яки) электрон)

________________________________________

юридик затлар өчен:оешма атамасы, адрес
(почта һәм(яки) электрон)

**Техник хатаны (ялгыш язуларны, басма хаталарны, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза**

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында җибәрелгән хата (ялгыш язулар, басма хаталар, грамматик яки арифметик хата) турында хәбәр итәм

______________________________________________________________________

(хезмәт күрсәтү атамасы)

Язылган: __________________________________________________________

______________________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар: ______________________________________________

______________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны (ялгыш язулар, басма хаталарны, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтүне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документка тиешле үзгәрешләрне кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны теркәп бирәм:

1.

2.

3.

Җибәрелгән техник хатаны (ялгыш язу, басма хата, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул иткән очракта, андый карарны җибәрүне сорыйм:

Электрон документ җибәрү юлы белән, E-mail адресына: ________________________;

расланган күчермә рәвешендә кәгазьдә почта аша түбәндәге адреска җибәреп: ________________________________________________________________.

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), файдалану, тарату (шул исәптән бирү), исемсезләү, тыю, персональ мәгълүматларны юк итү, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларыда

персональ мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле бүтән төр гамәлләр), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның алар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында карарлар кабул итүен дә кертеп, үз ризалыгымны, шулай ук мин вәкиле булып торган затның ризалыгын раслыйм.


Моның белән раслыйм: гаризага кертелгән, минем шәхескә һәм мин вәкиле булып торган зат шәхесенә кагылышлы мәгълүматлар, шулай ук минем тарафтан түбәндәрәк кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәп бирелгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм алардагы мәгълүматлар дөрес.


Миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәте сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда ________________телефоны буенча катнашырга ризалыгымны бирәм.

____________________ ______________ (_______________________)
(дата) (имза) (Ф.И.О.).

Региональ дәрәҗәдәге объектларга
дәүләт экологик экспертизасы оештыру
һәм үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
Административ регламентына
Кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы




2
Руководитель отдела назначает ответственного секретаря
Состав экспертной комиссии, сроки проведения ГЭЭ и задание экспертной комиссии утверждаются приказом Министерства
Проводятся заседания экспертной комиссии, на которые при необходимости приглашается заявитель
Включение дополнительных экспертов оформляется приказом Министерства
Необходимо продление срока проведения ГЭЭ
да
Продление срока проведения ГЭЭ оформляется приказом Министерства
нет
Необходимо представление дополнительных материалов
да
Отв.секретарь направляет заявителю уведомление о необходимости представления дополнительных материалов
Заявитель предоставляет необходимые материалы
нет
да
Необходимо привлечение дополнительных экспертов
нет
Руководитель экспертной комиссии организует подготовку проекта сводного заключения ГЭЭ
Проводится заключительное заседание с приглашением заявителя, представителей общественных организаций (в случае необходимости)
нет
Заключение подписано членами экспертной комиссии в полном составе
Отв.исполнитель направляет смету и счет на оплату с уведомлением о необходимости оплаты включения дополнительных экспертов
да
Заключение ГЭЭ утверждается приказом Министерства
Счет оплачен (представлена копия платежного поручения)
Заключение ГЭЭ направляется заявителю
Включение дополнительных экспертов и продление сроков оформляется приказом Министерства
Информация о заключении ГЭЭ направляется территориальным управлениям Министерства и органам местного самоуправления и в случаях, определяемых федеральным органом исполнительной власти в области экологической экспертизы кредитным организациям, которые осуществляют финансирование реализации объекта ГЭЭ
Проводится заключительное заседание с приглашением заявителя, представителей общественных организаций (в случае необходимости)
Заключение положительное
да
нет
Реализация объекта
Запрет реализации объекта

Региональ дәрәҗәдәге объектларга
дәүләт экологик экспертизасы оештыру
һәм үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
Административ регламентына
Кушымта (белешмәлек)

Региональ дәрәҗәдәге объектларга дәүләт экологик экспертизасы оештыру һәм үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы органнарның һәм вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр – Габделганиев Фәрит Солтанович | 267-68-01 | Farid.Abdulganiev@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары - Камалов Рөстәм Илдарович | 267-68-90 | Rustem.Kamalovl@tatar.ru |
| Дәүләт экологик экспертизасы һәм әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны нормалаштыру идарәсе башлыгы– Шаһидуллина Рәисә Абдулловна | 267-68-90 | Raisa.Shagidullina@tatar.ru |
| Дәүләт экологик экспертизасы бүлеге башлыгы - Манидичева Ольга Владимировна | 267-68-31 | Olga.Manidicheva@tatar.ru |
| Документлар үтәлешен контрольдә тоту блеге башлыгы - Ханнанова Гөлнара Расилевна | 267-68-04<br>267-68-05 | eco@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Җир асты байлыкларын, табигый ресурсларны файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре буенча бүлек башлыгы - Фәсхетдинов Марат Гайсович | 264-77-78 | Marat.Fashutdinov@tatar.ru |